ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2020 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында

2020 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

финанс-икътисадый вәзгыять начарлану куркынычы булган шартларда Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчаларыннан файдалануга контрольлек иткәндә яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә оешмаларга, индивидуаль эшкуарларга һәм гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә дәүләт ярдәме чараларын һәм субсидияләр бирүне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чыгымнарның нәтиҗәлелеген һәм сакчыллыгын бәяләү мәсьәләләренә аеруча игътибар бирергә;

Татарстан Республикасында илкүләм проектларны тормышка ашыруга һәм илкүләм максатларга ирешүгә контрольлек итүне дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына һәм аларга үзгәрешләргә финанс-икътисадый экспертиза, программа чараларының максатчан индикаторларга ирешүенә анализ ясау эшен дәвам итәргә;

контроль-хисап органнарын оештыруны һәм аларның эшчәнлеген федераль җайга салуда яңалыкларга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында»

Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен камилләштерү буенча өстәмә тәкъдимнәр кертергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 8 июле
№ 1046-VI ДС